ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2023 с.Старое Дрожжаное № 277

Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеген оештыру турындагы карарны үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсенең 2023 елның 15 маендагы П06-18/2023 номерлы монополиягә каршы законнарны бозуның билгеләрен үз эченә алган гамәлләрне (гамәл кылмауны) туктату турында кисәтүне исәпкә алып, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» Федераль законга һәм «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 485-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеген оештыру турында» 2022 елның 27 октябрендәге 568 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Прогресс» муниципаль унитар предприятиесе директоры Е.Н. Иванцовка Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Прогресс» муниципаль унитар предприятиесе уставына һәм эшчәнлек төрләре исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов